Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча

# НӘТИҖӘ

Арча шәһәре 2026 елның 20 марты

Ачык тыңлаулар уздыру урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27нче йорт

Ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты: 2026 елның 20 марты 16 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр.

Ачык тыңлауларның инициаторы: Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы.

Ачык тыңлаулар уздыру өчен нигез: “Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 маддәсе, “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында” Арча район Советының 2026 елның 9 февралендәге 30 номерлы карары, “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгының 2026 елның 19 февралендәге 6 номерлы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында” карары.

Ачык тыңлауларда каралган мәсьәләнең исеме: “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Иске Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турында”

Ачык тыңлаулар турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы: ачык тыңлаулар уздыру турында мәгълүмати белдерү (Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгының 2026 елның 13 февралендәге карары):

- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында;
- Арча шәһәре территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат

стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 17 йорт; Арча шәһәре, Х.Такташ ур., 58 йорт; Арча шәһәре, Кленовая ур., 4 йорт; Арча шәһәре, Банк ур., 2а йорт.

Ачык тыңлауларда катнашучылар саны турында белешмәләр: 42 кеше: "Арча шгәһәре" муниципаль берәмлеге хэзмәткәрләре- 5, депутатлар- 12, комиссия әгъзалары-6, җирлектә яшәүчеләр-19.

Ачык тыңлауларда каралган мәсьәлә буенча Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрдән язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртүне хупларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәр Советына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Иске Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләренә керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләренә кертү юлы белән "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге халкынан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртүгә халыкның ризалыгын белдерергә тәкъдим итәргә.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарылырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Арча шәһәренең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка игълан ителергә тиеш: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 17 йорт; Арча шәһәре, Х.Такташ ур., 58 йорт; Арча шәһәре, Кленовая ур., 4 йорт; Арча шәһәре, Банк ур., 2а йорт.

Рәис Г.Г.Ибәтуллина

Сәркатип Г.Х.Нигмәдҗанова